ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 февраля 2018 № 804

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Таң» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карарына, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карарына туры китереп

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Таң» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 15 февралендәге
804 нче карарына
кушымта

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең
«Таң» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле
өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | Сәламәтләндерү үзәге хезмәтләре | сум/сәгать | 500,00 |
| 2. | Уен залы хезмәтләре | сум/сәгать | 1300,00 |
| 3. | Ярышлар/чаралар үткәрү | сум/сәгать | 1600,00 |
| 4. | Өстәл теннисы хезмәтләре | сум/сәгать | 150,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова